РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» май 2019 ел г. Альметьевск № 1009

Әлмәт муниципаль районы
башкарма комитетының
2015 ел 16 октябрь № 1175
« Хроник бөер авырулы, амбулатор
ысул белән хроник гемодиализ алып
дәваланучы затларга социаль ярдәм чаралары
күрсәтү турында»гы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Әлмәт шәһәре территориясендә яшәүче, хроник бөер авырулы, амбулатор ысул белән хроник гемодиализ алып дәваланучы затларга адреслы социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатыннан,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетның 2015 ел 16 октябрь № 1175 « Хроник бөер авырулы, амбулатор ысул белән хроник гемодиализ алып дәваланучы затларга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"- Әлмәт шәһәре һәм Түбән Мактама шәһәр тибындагы поселогы территориясендә яшәүчеләргә -1 мең 800 сум».

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Шәйдуллина З.Р.) бюджет үтәлеше барышында өстәмә керә торган акчалар хисабына амбулатор хроник гемодиализ ысулы белән дәваланучы затларга социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыруга акча бүлеп бирүне күздә тотуны тәкъдим итәргә.

3. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны "Альметьевский вестник" газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Зак. № 3063